**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

# КАРАР

чираттан тыш утырыш

17 март 2020 ел № 13 Уруссу ш. т. п.

«2019-2023 елларга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районында кече һәм урта
эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү"
муниципаль программасына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 07 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү" муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа чаралары исемлеген № 1 Кушымта дип санарга;

"Программа чаралары исемлеге " №1 кушымтага түбәндәге эчтәлекле 29.1 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 29.1 | Исемлеккә кертелгән муниципаль милекне бирү эшен камилләштерү:<br><br>- Ютазы муниципаль районы кече һәм урта эшмәкәрлек (КУЭ) субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү өлкәсендә | Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 2020-2023 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эшче төркем төзү;<br><br>-Ютазы муниципаль районының муниципаль милеге Исемлеген тулыландыру өчен муниципаль милекне ачыклау;<br><br>- муниципаль ММЧда һәм мәгълүмати сайтларда КУЭ субъектлары өчен мөлкәт буенча ел саен мәгълүмати кампанияләр үткәрү;<br><br>- мөлкәтне арендага бирү буенча сату үткәрү турында карар кабул иткәндә гариза принцибын куллану ; | | |

программага «КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча максатчан күрсәткечләр " №2 кушымтаны түбәндәге редакциядә кертергә:

Кушымта № 2

## КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча максатчан күрсәткечләр

| № т/б | Максатчан күрсәткеч | База төшенчәсе | | Чор, ел | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Әһәмияте | Дата | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | Ел саен Россия Федерациясе субъектларында (бер.) дәүләт мөлкәте исемлекләрендә һәм муниципаль мөлкәт исемлекләрендә мөлкәт объектлары санының кимендә 10% ка артуы | 2 | | 2 | 4 | 6 | 8 | 10 | 12 |
| 1.1. Казнаның дәүләти (муниципаль) милке объектлары | | | | | | | | | |
| 1.1.1 | Җир кишәрлекләре (төрле билгеләнештәге) | 0 | | 0 | 2 | 4 | 6 | 8 | 10 |
| 1.1.2 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге жир кишәрлекләре | | | - | - | - | - | - | - |
| 1.1.3 | Күчемсез мөлкәтнең бүтән объектлары | 2 | | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| 1.1.4 | Күчемле милек | | | | | | | | |
| 1.2. Дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәт | | | | | | | | | |
| 1.2.1 | Күчемсез милек | | | | | | | | |
| 1.2.2 | Күчемле милек | | | | | | | | |
| 2. | Исемлектә (процентларда) мөлкәтнең гомуми санына карата аренда шартнамәләре өлеше) | | | | | | | | |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Ютазы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары З. М. Әгълиева